# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2021 елның 13 июле №45

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 250 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 22 апрелендәге 272 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 250 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (2020 елның 22 апрелендәге 272 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7.1 пунктын киләсе эчтәлек белән тулыландырырга:

1.7.1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

1.2. 3.5 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыру Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**